**Татарстан Республикасы Хисап палатасы**

# 2011 елда
# Татарстан Республикасы Хисап палатасы эше турында
# ХИСАП

**Казан – 2012 ел**

# 2011 елда
# Татарстан Республикасы Хисап палатасы эше турында
# Хисап

Эчтәлек


Эшчәнлекнең төп күрсәткечләре....................3

Экспертиза-аналитика эшчәнлеге....................5

Тикшерү-ревизия эшчәнлеге....................10

Россия Федерациясе Хисап палатасы, Россия Федерациясе субъектлары һәм муниципаль берәмлекләре тикшерү-хисап органнары белән үзара хезмәттәшлек....................25

2011 елда  Россия Федерациясе Хисап палатасы, Россия Федерациясе тикшерү-хисап органнары ассоциациясе (АКСОР) һәм Россиянең муниципаль берәмлекләре тикшерү-хисап органнары союзы белән хезмәттәшлекне үстерү һәм ныгыту буенча эш дәвам иттерелде....................25

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм хокук саклау органнары белән хезмәттәшлек....................29

Эшчәнлектә хәбәрдарлык....................30

## 2011 елда
## Татарстан Республикасы Хисап палатасы эше турында Хисап

Татарстан Республикасы Хисап палатасы (алга таба – Хисап палатасы) эше турында хисап “Татарстан Республики Хисап палатасы турындагы” Законның 33 маддәсе нигезендә әзерләнде.

Хисапта закон тарафыннан билгеләнгән максат һәм вәкаләтләрне башкару буенча Хисап палатасының 2011 елдагы эшчәнлеге нәтиҗәләре тәкъдим ителде.

## Эшчәнлекнең төп күрсәткечләре

2011 елда Хисап палатасы тарафыннан республика бюджетын, Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджетын төзү һәм башкаруны тикшерү буенча, дәүләт милке белән идарә итү һәм файдалану өлкәсендә 162 тикшерү-ревизия һәм экспертиза-аналитика чарасы үткәрелде.

**Татарстан Республикасы Хисап палатасы тарафыннан башкарылган тикшерү чаралары динамикасы**




Татарстан Республикасы Дәүләт Советына 28, шул исәптән Татарстан Республикасы законнары проектларына – 20, Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе фонды бюджетын үтәү барышы турында – 8 бәяләмә юлланды.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына озак вакытка исәпләнгән максатчан программалар проектларына 8 бәяләмә тәкъдим ителде.

Хисап палатасы бәяләмәләрендә бәян ителгән тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләр нигездә норматив хокукый актларны эшләп бетергәндә һәм раслаганда истә тотылган.

Хисап палатасы эшчәнлегенең төп күрсәткечләре түбәндәге таблицада бирелде.

| **Күрсәткеч атамасы** | **2009 ел** | **2010 ел** | **2011 ел** |
|---|---|---|---|
| **I. Экспертиза-аналитика эшчәнлеге** | | | |
| Үткәрелгән экспертиза-аналитика чараларының гомуми саны | 100 | 104 | 112 |
| Әзерләнгән экспертиза бәяләмәләре | 26 | 33 | 47 |
| Әзерләнгән методик документлар | 3 | 3 | 2 |
| **II. Тикшерү-ревизия эшчәнлеге** | | | |
| Үткәрелгән тикшерү-ревизия чаралары саны | 48 | 51 | 50 |
| Тикшерү-ревизия чараларын үткәргән чакта колачланган объектлар саны (берәмлек) | 464 | 470 | 481 |
| Ачыкланган бозулар күләме (мең сумнарда) | 2 201 772,8 | 2 984 585,9 | 3 035 829,8 |
| **III. Тикшерү-ревизия һәм экспертиза-аналитика чаралары нәтиҗәләрен тормышка ашыру** | | | |
| Чаралар күрү өчен күрсәтмә юлланды | 40 | 54 | 59 |
| Бюджетка кайтарылган чаралар һәм күрелгән чаралар (мең сумнарда) | 1 454 450,0 | 1 750 696,8 | 1 922 464,6 |
| Прокуратура һәм хокук саклау органнарына юлланган тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча материаллар саны (берәмлек) | 51 | 57 | 55 |
| Хисап палатасы тикшерү материаллары буенча суд һәм башка вәкаләтле органнар тарафыннан административ җаваплылыкка тарту турында кабул ителгән карарлар саны | 66 | 71 | 35 |
| Татарстан Республикасы Хисап палатасы материаллары буенча ачылган җинаять эшләре саны | 3 | 1 | 3 |

“Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында” Татарстан Республикасы Законы һәм Хисап палатасы регламенты нигезендә, Хисап палатасы эшчәнлеген эчке планлаштыру һәм оештыру мәсьәләләре, тикшерү-ревизия һәм экспертиза-аналитика чаралары нәтиҗәләре Хисап палатасы Коллегияләре утырышларында каралды. Коллегияләрдә 27 карар кабул ителде, 64 мәсьәлә каралды.

## Экспертиза-аналитика эшчәнлеге

2011 елда Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды (алга таба – ММИ Фонды) бюджеты үтәлешен беренчел, агымдагы һәм дәвамлы тикшерүне тәэмин итү максатында 112 экспертиза-аналитика чаралары үткәрелде. Аның нәтиҗәләре Хисап палатасы бәяләмәләрендә чагылыш тапты һәм тикшерү-ревизия чараларын планлаштырган чакта кулланылды. 2007-2011 елларда үткәрелгән экспертиза-аналитика чаралары динамикасы диаграммада тәкъдим ителде.

**Хисап палатасы тарафыннан үткәрелгән экспертиза-аналитика чаралары һәм әзерләнгән эксперт бәяләмәләре динамикасы**




**Беренчел тикшерү** кысаларында хисап елында Татарстан Республикасының 18 закон проектына, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты һәм ММИ Фонды бюджеты турындагы закон проектларына экспертиза үткәрелде һәм тиешле законнарга үзгәрешләр кертелде.

Экспертизалар нәтиҗәләре буенча Хисап палатасы бәяләмәләре Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлланды.

**“2012 елга һәм 2013 һәм 2014 еллар планлы вакытына Татарстан Республикасы бюджеты турында”** закон проектына бәяләмәдә бюджет проектын төзегән чакта кабул ителгән төп макроикътисадый күрсәткечләр республика икътисады үсешенең урнашкан тенденцияләрен һәм үсешнең федераль дәрәҗәдәге уртача оптимистик варианты сценарий шартларында барлыкка килгән тенденцияләрен  истә тотып билгеләнде.

Хисап палатасы тарафыннан,  киләсе елга федераль бюджет проекты күрсәткечләрен истә тотып, республика бюджетына килгән кире кайтарылмый торган керемнәрнең аерым төрләре буенча күләмен тәгаенләргә, шулай ук 2012 елда республика бюджеты керемнәрендә алдагы елларда бирелгән кредитлар буенча процентлар түләүдән килгән чараларны карарга тәкъдим ителде.

2012 елга һәм 2013 һәм 2014 еллар планлы вакытына республика бюджеты проекты тарафыннан игълан ителгән республика бюджетыннан финансланырга тиешле норматив йөкләмәләрне башкаруга, социаль йөкләмәләр күләмен индексацияләүне истә тотып, бюджет ассигнованияләре каралган. Бу исә гражданнарга социаль ярдәм чаралары комплексын саклауны тәэмин итә.

**“2012 елга һәм 2013 һәм 2014 еллар планлы вакытына Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджеты турында”** закон проектына бәяәмәдә ММИ Фонды бюджетының керем өлешендә артым резервлары булуы, шулай ук 2013 һәм 2014 елларга федераль дәрәҗәдә бюджетара трансфертларны закон тарафыннан билгеләнгәннән кимрәк күләмдә бүлгән очракта Фонд бюджетының баланслылыгы юкка чыгу куркынычы барлыгы билгеләп үтелде.

**2011 елга һәм 2012 һәм 2013 еллар планлы вакытына Татарстан Республикасы бюджеты һәм ММИ Фонды бюджеты турындагы** законнарга үзгәрешләр кертү нигездә салым һәм салым булмаган керемнәрнең аерым төрләре буенча керемнәрнең фаразланган күрсәткечләрен, федераль бюджеттан, Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан кире кайтарылмый торган керемнәрне тәгаенләү, ММИ

Федераль фонды һәм Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм фонды бюджетларыннан, шулай ук чыгымнарның аерым төрләре буенча бюджет ассигнованиеләрен тәгаенләү һәм яңадан бүлү белән бәйле.

Үзгәрешләр кертү турындагы закон проектларына бәяләмәләрдә, хисап елында фактик үтәлешне истә тоткан хәлдә, бюджет күрсәткечләрен тәгаенләү буенча кисәтүләр һәм тәкъдимнәр ясалды.

**“2011-2015 елларга Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый үсеш программасын раслау турында”** Татарстан Республикасы законы проектын экспертизалау нәтиҗәләре буенча, куелган максатлардан чыгып, Программаны тормышка ашыру максатчан индикаторларының тәгаенләүне таләп иткәнлеге, аерым индикаторлар буенча сан характеристикалары булмау ачыкланды. Хисап палатасы тарафыннан Программаны тормышка ашыруның тикшерү этапларының һәм арадаш күрсәткечләрнең билгесез булуы билгеләп, шулай ук, Программа проектында салынган максатчан индикаторларны исәпкә алган хәлдә, алдарак озак вакытка кабул ителгән максатчан программалар күрсәткечләрен яңадан карап чыгу кирәклеге билгеләнеп үтелде.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары тарафыннан расланган озак вакытка исәпләнгән максатчан программаларны эшләү һәм тормышка ашыру тәртибе нигезендә Хисап палатасына юлланган озак вакытка исәпләнгән 8 максатчан республика программасы проектларына экспертиза ясалды. Экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына юлланды. Хисап палатасының кисәтү һәм тәкъдимнәре түбәндәге программаларны эшләп бетергән чакта истә тотылды:

- **2011-2015 елларга торак төзелешен үстерү программасы буенча** Программаны эшләгән вакытта кабул ителгән 2010 ел база күрсәткечләре тәгаенләнде, исәп-хисап ясаганда кулланылучы индекс-дефляторлар һәм аерым сан күрсәткечләре яңадан карап чыгылды.

Моннан тыш, Хисап палатасы тәкъдиме буенча төзелеш тармагындагы кадрлар белән тәэмин ителү мәсьәләсен хәл итү өчен Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан тиешле подпрограмма эшләнде.

- **2012-2014 елларга Коррупциягә каршы республика программасы** буенча Хисап палатасы кисәтүләре буенча Программаны

финанслау күләме тәгаенләнде, программаны тормышка ашыру этаплары буенча финанслау күләме бүленде, соңгы нәтиҗәне бәяләү индикаторлары тәгаенләнде;

- **2011-2015 елларга Татарстан Республикасы Транспорт комплексы үсеше программасы** буенча Программа күрсәткечләре тәгаенләнде;

- **“2011-2013 елларда Административ киртәләрне киметү, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүне оптимизацияләү һәм сыйфатын арттыру” программасы** буенча финанслау күләме һәм чыганаклары бигеләнде, тормышка ашыру механизмы ачыкланды.

Татарстан Республикасы бюджеты һәм ММИ Фонды бюджеты үтәлешен **оператив тикшерү** үз эченә республика бюджеты керем һәм чыгым маддәләренең күләм һәм түзелеш буенча вакытында үтәлешне, шул исәптән башкарылган чыгымнарның законлылыгын, игълан ителгән норматив йөкләмәләр үтәлешен, бюджет дефицитын финанслау чыганакларыннан чаралар җәлеп иткән чакта куелган чикләүләрне үтәүне, дәүләт бурычы хәлен, бюджет алучыларның дебитор һәм кредит бурычы күләмен, Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелгән кредитлар буенча бурыч күләмен, республика максатчан программаларын тикшерүне ала.

Татарстан Республикасы бюджеты, ММИ Фонды бюджеты үтәлешен оператив тикшерү нәтиҗәләре Хисап палатасының квартал саен Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына юллана торган бәяләмәләрендә чагылыш тапты.

Хисап палатасы бәяләмәләрендә Татарстан Республикасы бюджеты, ММИ Фонды бюджеты үтәлешенең фактик дәрәҗәсе закон тарафыннан расланган күрсәткечләр белән чагыштыруда тәкъдим ителә, бюджет процессында катнашучыларның кайберләре эшчәнлегендә ачыкланган бозулар һәм кимчелекләр билгеләп үтелә һәм аларны юкка чыгару буенча күрсәтмәләр бирелә.

**Дәвамлы тикшерү** кысаларында бюджет законнары нигезендә **2010 ел өчен Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында хисапка** тышкы тикшерү үткәрелде. Бюджет чараларыннан төп 32 кулланучының еллык бюджет хисабына тикшерү үткәрелде. Хисап палатасы тарафыннан кимчелекләр ачыкланды (алар хисап күрсәткечләренең дөреслелегенә тәэсир

итмәгән). Бюджет законнарын бозган министрлык һәм ведомстволарга Хисап палатасы күрсәтмәләре юлланды.

2010 ел өчен Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында хисапка бәяләмәдә бюджетның фактик керемнәре һәм чыгымнарын анализлау нәтиҗәләре, шулай ук закон тарафыннан расланган күрсәткеч бирелде.

Тышкы яктан тикшерү нәтиҗәләре буенча 2010 ел өчен бюджет үтәлеше турында Хисап мәгълүматларының закон тарафыннан расланган күрсәткечтән тайпылышы объектив характерга ия һәм түбәндәге сәбәпләргә бәйле булуы билгеләнде:

- Хисап елының декабрь ае азагында федераль бюджеттан чаралар килү;
- Сатып-алу бәйгеләрен үткәрү нәтиҗәләре буенча бюджет алучылар тарафыннан чараларны янга калдыру;
- Дәүләт ихтыяҗы өчен эшләрне кабул итү буенча процедуралар хисап елы азагында тамамланмаган.

Аерым категория гражданнарга түләүләр формасында социаль ярдәмгә чыгымнар тулы күләмдә үтәлмәгән, бу нигездә чараларны гариза нигезендә бирүгә бәйле.

Шулай ук бәяләмәдә 2010 ел бюджетын үтәгән вакытта бюджет законнары нормаларын, бюджет турындагы закон нигезләмәләрен бозулар ачыкланды, бюджет чараларын максаттан тыш һәм нәтиҗәсез куллану очраклары билгеләнде.

**“2010 ел өчен Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында”** Татарстан Республикасы законы проектын экспертизалау нәтиҗәләре буенча Закон проектында чагылыш тапкан республика бюджеты үтәлеше күрсәткечләренең 2010 ел өчен бюджет үтәлеше турында Хисапның шундый ук күрсәткечләренә туры килгәнлеге ачыкланды.

**2010 ел өчен ММИ Фонды бюджеты үтәлеше турында Хисап**ны тышкы яктан тикшерү кысаларында ММИ Фонды бюджетына килгән керемнәрне чагылдырган вакытта бозулар килеп чыгу ачыкланды. Хисап палатасы кисәтүләре икенче укылышка төзәтүләр формасында исәпкә алынды.

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44 маддәсе нигезендә 2011 елда 2010 ел өчен югары дотациягә ия булган 12 муниципаль районның бюджет үтәлеше турындагы еллык хисапларын эчке яктан тикшерү үткәрелде, тикшерү нәтиҗәләре һәм муниципаль район бюджетлары турындагы карарларны үтәүне бәяләү Хисап палатасы бәяләмәләрендә тәкъдим ителде.

Әлеге эш юнәлеше буенча ачыкланган типик бозуларга түбәндәгеләр керә: киләсе финанс елы түләүләре хисабына чыгымнар (арттырып түләүләр) ясау, муниципаль бурыч күләме өлкәсендә бюджет турындагы карарлар тарафыннан билгеләнгән чикләүләрне үтәмәү, бюджет кулланучылары тарафыннан билгеләнгән еллык лимиттан артыграк күләмдә йөкләмәләр кабул итү.

Киләсе елларда бюджет процессын муниципаль районнарда тормышка ашырган вакытта шундый ук бозуларны булдырмау максатында, муниципаль берәмлекләр бюджеты үтәлеше турында хисапларны эчке яктан тикшерү нәтиҗәләре турында Хисап палатасы бәяләмәләре тикшерелгән муниципаль район хакимияте башлыкларына юлланды.

## Тикшерү-ревизия эшчәнлеге

2011 елда Хисап палатасы тарафыннан **50** тикшерү-ревизия чарасы үткәрелде, **481** объект тикшерелде. Тикшерелгән чаралар күләме **109 428 777** мең сум тәшкил итте.

Татарстан Республикасы бюджеты үтәлешенең аерым мәсьәләләре буенча, 2010 ел өчен бюджет хисабын тышкы яктан тикшерү чаралары 9 министрлыкта, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына караган учреждение һәм оешмаларда, 10 муниципаль берәмлектә үткәрелде.

Республика Президенты йөкләмәсе буенча – 5, Дәүләт Советы йөкләмәсе буенча 2 тикшерү чарасы үткәрелде.

Хисап чорында **Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм аңа караган учреждениеләр тарафыннан энергетика ресурслары кулланылган чакта бюджет чараларын файдалануның нәтиҗәлелек аудитына** йомгак ясалды.

Аудит барышында гомуми күләме 182,8 млн. сумлык бозу ачыкланды, шул исәптән 141,2 млн. сум акча нәтиҗәсез кулланылган.

Энергия ресурсларын җитештерүдән тыш чыгымлау килеп чыгу һәм энергия куллану нормативларын үтәмәү нәтиҗәсендә, министрлык һәм аңа караган учреждениеләр тарафыннан 4 ел эчендә 113,4 млн. сумга күбрәк, ягъни коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә тотылган чараларның гомуми күләмендә 37,3% бюджет чаралары сарыф ителгән.

Нәтиҗәлелек аудиты министрлыкка караган учреждениеләрнең барысы да "Энергияне саклау һәм энергетик нәтиҗәлелекне арттыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 261-ФЗ номерлы Федераль законның кулланылган энергия ресурслары күләмен өч проценттан да кимрәк булмаган күләмгә киметү турындагы таләпләрен үтәүне тәэмин итмәгәнлекне күрсәтте. Шулай, кулланылган энергия ресурсларының күләмен киметү тәэмин ителмәде: җылылык буенча – 60% ведомствога караган учреждениедә; электр энергиясе буенча – 68%ында; су буенча – 52%ында һәм газ буенча – 71% учреждениедә.

Энергия саклау өлкәсендә норматив-хокукый документларны анализлау республикада энергияне саклау буенча дәүләт сәясәтен тормышка ашыру һәм энергетик нәтиҗәлелекне арттыру өчен кирәкле шартлар булдырылганлыкны күрсәтте.

Үткәрелгән аудит барышында алынган нәтиҗәләр энергияне саклау өлкәсендәге эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген арттыру резервлары барлыгын раслый.

**Кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү, инвестицион активлыкка этәргеч ясау** һәм **инновацион эшчәнлекне үстерүгә** бүлеп бирелгән дәүләт чараларын куллануның нәтиҗәлелегенә аудит үткәрүгә йомгак ясалды.

Татарстан Республикасында эшмәкрлеккә ярдәм итү һәм инновацион эшчәнлекне үстерүгә дәүләт ярдәме системасының төп элементлары төзелгән. Тиешле норматив-хокукый документлар кабул ителгән. IT-парк, "Алабуга" махсус икътисадый зонасы, технопарк һәм бизнес-инкубаторлар эшли. Кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү буенча подпрограмма һәм проектлар комплексы тормышка ашырыла. 2004-2010 елларда әлеге максатларга 23 млрд. сумнан артыграк чара бүлеп бирелгән.

Шуның белән бергә, нәтиҗәлелек аудиты йомгаклары кече эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итүгә юнәлдерелгән бюджет чараларын куллануның нәтиҗәлелеген арттыру резервлары барлыгын күрсәтте.

Татарстан Республикасы Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү комитеты тарафыннан грант чаралары хисабыннан ярдәм ителгән бизнес-проектларны

тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген мониторинглау тиешле дәрәҗәдә тәэмин ителмәгән. Килешүләр шартын бозып, кече эшмәкәрлек субъектларын тарафыннан бюджет чараларын куллану турында хисаплар үз вакытында тапшырылмаган.

Татарстан Республикасы Инвестиция-венчур фонды эшчәнлеген тикшерү барышында “Татарстан Республикасы өчен илле иң яхшы инновацияле идея” еллык республика бәйгесе һәм “Идея-1000” инновацияле проектлар программасы җиңүчеләрнең грант чарарының бер өлешен (35%ка кадәр) уку, бухгалтерлык, юридик ярдәм һәм өстәмә тикшерүләр уздырган өчен Фонд тарафыннан билгеләнгән оешмаларга күчергәнлекләре ачыкланды.

“Идея” технопаркында кулланылышта булмаган 23,2 млн. сумлык җиһаз табылды.

Куелган таләпләрне бозып, кече эшмәкәрлек субъектлары булмаган предприятиләр белән гомуми күләме 43,7 млн. сумлык лизинг килешүләре финансланган.

Чистай шәһәрендә ачылган Бизнес-инкубатор ачылганнан соң бер ел вакыт дәвамында тулы күләмдә эшләмәгән. Аудит барышында “Чистай шәһәре бизнес-инкубаторы” дәүләт автоном учреждениесен төзү турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (2010 елның 28 апрелендә кул куелган 304 номерлы карар) кабул ителде.

Бизнес-инкубаторларда резидентлар урнаштыруга бәйге үткәрү процедурасы кайбер очракларда бик озакка сузылган, аны үткәрүнең анык тәртибе (регламенты) расланмаган. Бу җәһәттән бизнес-инкубатор биналары озак вакыт басып торган, кайбер очракларда резидентлар законны бозуп бәйге үткәреп тормыйча гына урнашкан. Тикшерү чарасы барышында Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен арендага бирүне килештерү тәртибен раслау буенча боерык кабул ителде.

Үткәрелгән нәтиҗәлелек аудиты йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Хисап палатасы тарафыннан кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итүгә бүлеп бирелгән дәүләт чараларын куллануның нәтиҗәлелеген арттыруга, инвестицион активлыкка этәргеч ясау һәм инновацион эшчәнлекне үстеүгә юнәлдерелгән 50дән артык киңәш-тәкъдим әзерләнде.

Бизнес-инкубаторлар өчен 2011 ел һәм 2012 һәм 2013 еллар планлы вакытына дәүләт йөкләмәсендә эшчәнлек нәтиҗәлелеге күрсәткечләре расланды. 2005-2010 елларга кече эшмәкәрлеккә ярдәм итү программасының

аерым положениеләрен тормышка ашырудагы Хисап палатасы тарафыннан ачыкланган кимчелекләр 2011-2013 елларга Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү республика программасын (2010 елның 30 декабрендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 1151 номерлы карары тарафыннан расланды) эшләгән чакта истә тотылды.

Татарстан Республикасы икътисадына инвестицияләр җәлеп итү буенча эшчәнлекне камилләштерү, инвестицион проектларны тормышка ашыруда комплекслы ярдәмне тәэмин итү максатында, 2011 елның 1 июнендә кул куелган УП-298 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы белән Татарстан Республикасы Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү комитеты Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы итеп үзгәртелде.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы йөкләмәсе** нигезендә **республика балалары һәм яшьләренең ялын, савыктыруын һәм мәшгульлеген оештыру программалары чараларын тормышка ашыруга һәм аерым категория гражданнарны дару һәм медицина билгеләнешендәге эшләнмәләр белән тәэмин итү буенча дәүләт социаль ярдәмен күрсәтүгә** бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты чараларын максатчан һәм нәтиҗәле куллануны тикшерү үткәрелде.

Ел саен **балалар һәм яшьләрнең ялын һәм савыктыруын оештыру** буенча чаралар республиканың Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган тиешле Программалар кысаларында тормышка ашырыла.

Тикшерү нәтиҗәләре тикшерелгән чорда ял итүне оештыруның барлык төрләре буенча балалар һәм яшьләрне колачлауның уңай динамикасы турында сөйли, 2010 елда ял иткән балалар саны 29462 кешегә, ягъни 2009 ел белән чагыштырганда 16,0%ка арткан.

Тикшерү барышында аерым очракларда азык-төлек продуктлары чамадан тыш артык бәядән (базар бәяләре белән чагыштырганда) сатып алу, балаларны сәламәтләндерү лагерьларына контракт шартлары белән чагыштырганда түбәнрәк сорттагы продуктлар китерү ачыкланды.

Шулай, “Толедо” ҖЧҖ тарафыннан китерелгән сыйфат дәрәҗәсе муниципаль контрактлар таләбенә туры килмәгән азык-төлек продуктларының гомуми бәясе 2 906,8 мең сум тәшкил иткән. Муниципаль контракт кысаларында китерелгән икмәк продуктарының бәясе Казан шәһәре берәмтекләп сату челтәрендәге бәядән 25%ка артыграк булуы ачыкланды.

Эшнең вакытлыча булуы һәм түбән хезмәт хакын истә тотып, лагерьларны кадрлар: табиб-педиатрлар, пешекчеләр, ашханәдәге пешекче ярдәмчеләре белән тәэмин итүдә кыенлыклар булуы билгеләп үтелде.

Мәсәлән, республика сәламәтләндерх лагерьларында табиб-терапевтлар белән тәэмин ителеш түбәндәгечә булган: 2009 елда – булган ихтыяҗның 33%, 2010 елда – 28%, 2011 елда – 25%. Калган лагерьларда балаларга медицина ярдәме күрсәтү урта медицина персоналы тарафыннан башкарылган.

Казан шәһәре прокуратурасы тарафыннан үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты рәисе исеменә бюджет законын бозуларны юкка чыгару турында тәкъдим кертелде.

Монополиягә каршы федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан Казан шәһәре Башкарма комитетының “Ял” Балалар һәм яшьләрнең ялын, савыктыруын һәм мәшгульлеген оештыру шәһәр үзәге” МУ директоры урынбасары административ җаваплылыкка тартылды – аңа 20 мең сум күләмендә штраф салынды.

**Аерым категория гражданнарны дарулар һәм медицина билгеләнешендәге эшләнмәләр белән тәэмин итү буенча дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә** финанслау күләме 2009-2010 елларда һәм 2011 елның беренче яртыеллыгында 988 млн. 153 мең сум тәшкил итте.

Ел саен льготалы дарулар белән тәэмин итүдә катнашучы дәвалау учреждениеләрнең саны кимү ачыкланды, бу республика халкы өчен күрсәтелгән льготаларның һәркем өчен дә мөмкин булуны юкка чыгара.

Сатып алынган дару чаралары һәм медицина бигеләнешендәге эшләнмәләрнең кирәклеген тикшерү тарафыннан аерым медикаментларның озак вакыт кулланылмавы ачыкланды. Шулай, медикаментларның бер өлеше кирәксез һәм складта, кайбер очракларда 2 елдан артык вакыт дәвамында, саклана.

**Татарстан Республикасы Президенты йөкләмәсе буенча** Хисап палатасы тарафыннан **“Татарстан Республикасы Ипотека агентлыгы” ААҖ** эшчәнлеген тикшерү үткәрелде.

Татарстан Республикасы бюджетыннан Ипотека агентлыгының уставлы капиталына 60 000 мең сум акча кертелде. Хәзерге вакытта акцияләрнең контроль пакеты – Татарстан Республикасы милкендә (51,28%). 2010 ел нәтиҗәләре буенча дәүләт акцияләре пакетының баланс бәясе 491 016 мең сум тәшкил итте.

2007 елдан башлап, акционерлык җәмгыятенең чиста табышы ел саен кимү тенденциясенә ия: 2007 елда 4 169 мең сумнан 2010 елда 102 мең сумга

кимегән. Бухгалтерлык хисабын анализлау нәтиҗәләре буенча “Татарстан Республикасы Ипотека агентлыгы” ААҖ финанс хәле канәгатьләндерерлек түгел дип бәяләнә.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына акционерлык җәмгыятенең хәлсезләнүен (банкротлылыгын) булдырмау буенча чараларны эшләү һәм тормышка ашыру өчен “Татарстан Республикасы Ипотека агентыгы” ААҖ финанс хәле турында мәгълүмат юлланды.

**Татарстан Республикасы Президенты йөкләмәсе** буенча 2011 елда Хисап палатасы тарафыннан биологик калдыкларны утилизацияләү инфраструктурасын төзүгә бүлеп бирелгән бюджет чараларын куллануны тикшерү үткәрелде.

Тикшерү чаралары барышында 6 633 мең сум күләмендә финанс бозулары ачыкланды.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә себер язвасыннан үлгән терлекләр күмелгән чокырларны капиталь ремонтлауга 2 918,1 мең сум күләмендә бүлеп бирелгән чаралар 3 елдан артык кулланылмый. Шулай ук 3 елдан артык вакыт буе биотермик чокырлар төзүгә киткән авыл хуҗалыгы оешмалары чыгымнарын каплау өчен бүлеп бирелгән 3 714,9 мең сум күләмендәге бюджет чаралары кирәк булмаган хәлдә кала бирә.

Себер язвасыннан үлгән терлекләр күмелгән чокырларны карап тоту буенча йөкләмәләр генераль подрядчы “Татагропромстрой” ААҖ тарафыннан ике елдан артык башкарылмый. Әмма Ветеринария идарәсе тарафыннан штраф санкцияләре, пени түләүләре түләттерелмәгән.

Муниципаль берәмлекләрдә биологик калдыкларны утильләштерү буенча чаралар  нигездә сатып алынган җайланмаларны кулланмыйча гына тормышка ашырыла.

**Татарстан Республикасы Президенты йөкләмәсе буенча** 2009-2011 елларда транспорт комплексын үстерүгә бүлеп бирелгән республика бюджеты чараларын максатчан һәм нәтиҗәле куллануны тикшерү үткәрелде. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы һәм “Главтатдортранс” ДКУ тарафыннан 113 621,8 мең сум күләмендә бюджет чараларын нәтиҗәсез куллану очрагы ачыкланды. Шулай, “СканТатАлабуга”

ҖЧҖ 2003 елдан бирле гомуми бәясе 66 541 мең сумлык СканТат-5226 маркалы 24 автобус белән тәэмин итмәгән. Министрлык тарафыннан дебиторлык бурычын кайтару буенча тиешле чаралар күрелмәгән.

“Главтатдортранс” ДКУ дебиторлык бурычы кире кайтарырлык күләмдә түгел, ул 47 031,9 мең сум, шул исәптән: “Нур-1” ҖЧҖ – 44 116,4 мең сум, “Технополис” ҖЧҖ – 1 111,1 мең сум, “Новые Тольяти” – ЯАҖ – 1 538,9 мең сум тәшкил итә.

**Татарстан Республикасы Президенты йөкләмәсе буенча** 2006-2011 елларда Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының штатлы санын оптимизацияләү мәсьәләсе буенча тикшерү-аналитика чарасы үткәрелде.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча муниципаль берәмлек дәрәҗәсендә кабул ителгән карарларның муниципаль берәмлекләргә җирле үзидарә органнары санын оптимизацияләү һәм аны арттырмау буенча карарлар кабул итүне булдырмау буенча тәкъдимнәрне үз эченә алган Татарстан Республикасы Президенты һәм Хөкүмәте карарларын, еллык законнар положениеләрен үтәүне тәэмин итмәгәнлеге ачыкланды.

Хисап палатасының тикшерү эшчәнлегендә бюджет чараларын бүлгәндә һәм кулланган һәм дәүләт һәм муниципаль милек белән идарә иткән вакытта **коррупциоген** факторларга һәм ихтималлылыкка игътибар бирелде.

Коррупция ихтималы югары булган бер тармак булып **дәүләт һәм муниципаль милек белән идарә итү һәм файдалану** тора.

Хисап чорында үткәрелгән комплекслы тикшерү һәм тематик тикшерү чараларының гомуми саныннан 20сендә дәүләт һәм муниципаль милек һәм җир биләмәләрен максаттан тыш куллану белән бәйле бозулар – аренда килешүләре буенча акчаларның килеп җитмәве, дәүләт һәм муниципаль милектә булган объектларны чит оешмаларга бушка бирү, тормышка ашырылучы милек һәм җир участокларының базар бәясен тушерү һ.б. ачыкланды.

Алабуга муниципаль районында үткәрелгән тикшеү М7 трассасындагы сәнәгать билгеләнешендә булган 1,5 га мәйдандагы җир биләмәсе 594 мең сум, ягъни кадастр бәясенә карата – 6 мәртәбә, базар бәясенә карата – 13 мәртәбә кимрәк бәягә тормышка ашырылганлыгын ачыклады.

Алабуга муниципаль районында аренда килешүләре үтәлешен тикшергән чакта аренда түләүләре буенча 18 891,3 мең сум күләмендә бурыч ачыкланды.

Аерым алганда, 2007 елда «Вершина И» ҖЧҖ нә автомобильләр юу бинасы һәм кафе өчен участок бирелгән. Аренда өчен 5 024,4 мең сум күләмендә түләү билгеләнгән, 50 мең сум түләнгән. Тикшерү вакытына (2011 елның мае) төп бурыч буенча бирелэсе акча 4 974,4 мең сум тәшкил итә.

Алабуга муниципаль районы Прокуратурасы үткәргән тикшерү нәтиҗәләре буенча муниципаль район башлыгы һәм Җир-мөлкәт палатасы исеменә 2 күрсәтмә кертелде.

Тәтеш муниципаль районы бюджетына тикшерү үткәрелгән вакытка 10405,6 мең сум күләмендә, шул исәптән җир участокларын арендага бирү һәм кулланудан - 10 379,2 мең сум табыш килеп җитмәгән.

Питрәч муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан муниципаль мөлкәтне тормышка ашыру буенча сату үткәрүгә аерым очракларда махсуслаштырылган оешмаларга кергән акчаларның 35%ына кадәр түләүләр белән килешүләр төзегән. Әлеге түләүләрнең тулаем күләме 2 168,4 мең сум тәшкил итте.

Питрәч районы Прокуратурасы үткәргән тикшерү нәтиҗәләре буенча Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, Питрәч һәм Кәрәш-Сәрде авыл җирлеге башлыклары, “Питрәч муниципаль районы идарәче компаниясе” ҖЧҖ директоры адресына күрсәтмәләр кертелде, 5 җаваплы зат дисциплинар җаваплылыкка тартылды. Моннан тыш, әлеге тикшерү материаллары карау һәм тиешле карар кабул итү өчен РФ Тикшерү комитетының ТР буенча тикшерү идарәсенең Питрәч районара бүлегенә юлланды.

Биектау муниципаль районында Хисап палатасы үткәргән бюджет чараларын куллануны тикшерү Красносельский авылы җирлеге башкарма комитетының муниципаль милек иясе (район башкарма комитеты) рөхсәтеннән башка Биектау райпосына Биектау торак урынын төзекләндерү белән бәйле эшләр буенча түләү бурычларын бетерү хисабына баланс бәясе 1 644 мең сум булган автотранспорт чарасын тапшыруны ачыклый. Шул ук вакытта тикшерү вакытында җирлек башкарма комитетының Биектау райпосына бурычы юк.

Биектау муниципаль районы Прокуратурасы үткәргән тикшерү нәтиҗәләре буенча Красносельский авылы җирлеге Башкарма комитеты адресына күрсәтмә кертелде. Күрсәтмә белән танышу нәтиҗәләре буенча бер вазыйфаи зат дисциплинар җаваплылыкка тартылды.

Казан һәм Яр Чаллы шәһәрләрендә урнашкан сугыш ветераннары өчен госпитальләрдә республика бюджеты һәм Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе фонды акчаларын куллануны тикшерү нәтиҗәләре буенча Казан шәһәренең “Сугыш ветераннары өчен госпиталь” ДССУндә арендатордан (“Сигма” ҖЧҖ) ул кулланган мәйданны тоту өчен коммуналь һәм эксплуатацияләү хезмәте чыгымнарын каплау буенча бурычны түләтү юнәлешендә чаралар күрелмәве ачыкланды.

Татарстан Республикасы Сәүдә һәм сәнәгать министрлыгында «Лучезарный плюс» ҖЧҖ 1 381,2 мең сумлык 950 берәмлек товар-матди байлык җаваплы саклауга бирелгән, шуларның күп өлеше фактта коммерциячел структураның үз эшчәнлегендә кулланылган. Үткәрелгән тикшерү нәтиҗәсендә Министрлык приказы белән 1 вазыйфаи зат дисциплинар җаваплылыкка тартылды.

Тикшерү барышында **дәүләт һәм муниципаль хаҗәтләр өчен заказлар урнаштыру өлкәсендә** бозулар ачыкланды, алар сатуларны оештыру процедурасы, төзелгән килешүләрнең шартларын товарларны китерү срокларын үтәү, товарларның бәясе һәм төрләнеше өлкәсендә нигезсез үзгәртү, авансла лимитларын арттыру, бәйге үткәрмичә генә килешүләр төзү һ.б. белән бәйле.

Мәсәлән, Зәй шәһәре башкарма комитеты тарафыннан сату үткәрү буенча кирәкле процедураларны үткәрмичә генә «Авантех» ҖЧҖ ышанычлы идарәсенә 6 300 мең сумлык автобуслар тапшырылган.

Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгының заказлар урнаштыру буенча Бердәм комиссиясе тарафыннан заказлар урнаштыруда катнашучыларга дәүләт заказлары турындагы законда каралмаган таләпләр куелу нәтиҗәсендә “...аукционда катнашу өчен гариза һәм аңа кушымталар исемлегенә кергән барлык документлар да (һәр бит тә) заказ урнаштыруда катнашучының вәкаләтле затның имзасы белән расланмаган, заказ урнаштыруда катнашучының мөһере белән беркетелмәгән” дигән сәбәп белән 22 045 мең сумлык капиталь төзекләндерү үткәрүгә 6 лот буенча заказ урнаштыруда катнашучылар ачык аукционда катнашуга кертелмәгән.

Хисап палатасы тарафыннан 2009-2010 елларда һәм 2011 елның 1 яртыеллыгында Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгына бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты чараларын максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тикшерү үткәрелде.

Министрлыкның 2009 елдан башлап ел саен «Инжиниринг» ҖЧҖ белән атмосфера һавасының сыйфатын тикшерү постларын тотуга килешүләр төзүе билгеле булды. 2011елның 1 гыйнваренә 12 127,5 мең сум акча түләнгән.

Килешүләргә техник бирем итеп приборларны тестлаштыру һәм калибрлауны үткәрү, атмосфера һавасының сыйфатын тикшерү буенча күчмә һәм автоматлаштырылган постларның үлчәү чараларын техник яктан тәэмин итү билгеләнде. Шуның белән бергә министрлыкта шул ук функцияне башкаручы аналитик тикшерүнең үзәкләштерелгән махсуслаштырылган инспекциясе дә бар.

Эшләрне үтәү һәм тотылган материалларны китереп тору өчен «Инжиниринг» ҖЧҖ “бер көнлек фирмалар” билгеләре булган оешмаларны җәлеп иткән. Килешүләрдә күрсәтелгән адреслар буенча «Массив К» ҖЧҖ, «МегоТранс» ҖЧҖ, «Элкотест» ҖЧҖ, «Комплект групп» ҖЧҖ бөтенләй юк.

Татарстан Республикасында дәүләт финанс күзәтүе мәсьәләләре буенча ведомствоара координацияләү советы утырышларында дәүләт һәм муниципаль хаҗәтләр өчен заказлар урнаштыру өлкәсендә бозуларны күп тапкырлар тикшерү нәтиҗәләре буенча Совет әгъзалары җаваплы вазыйфаи затларның гамәлен персональ бәяләү кирәк дигән нәтиҗәгә килде – килеп чыккан әлеге хәлдә коррупциягә хас күренешләрне ачыклау объекты булып дәүләт заказчыларының, товар, эш, хезмәт күрсәтүне кабул итүгә вәкаләтле вазыйфаи затларның гамәлләре торачак.

Хисап палатасы эшчәнлегенеңтагын бер юнәлеше булып **социаль-мәдәни объектларны, күпфатирлы торак йортларны капиталь төзекләндерүгә** бүлеп бирелгән бюджет акчаларын куллануны тикшерү тора.

2009-2011 елларда күпфатирлы өйләргә капиталь төзекләндерү республика программасын тормышка ашыруга бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджет чараларын максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тикшерү 10 муниципаль берәмлектә: Алексеевский, Баулы, Биектау, Алабуга, Яшел Үзән, Питрәч, Тәтеш, Тукай, Ютазы муниципаль районнарында һәм Казан шәһәрендә үткәрелде. Тикшерү барышында 16 657 мең сумлык закон бозулары ачыкланды.

Казан шәһәре Киров районында – 12 өй, Мәскәү районында – 12 өй, Идел буе районында – 20 өй, Яшел Үзән муниципаль районында 12 өйдә сыйфатсыз штукатур һәм буяу эшләре үткәрү ачыкланды.

Баулы шәһәрендә капиталь төзекләндерү вакытында күп җитешсезлекләр җибәрелгән. Нефтепровод урамында урнашкан 5 нче йортның цоколь өлешендә һәм балконда – штукатур эшләре, Октябрь мәйданы урамы, 9 нчы йортта түбәне төзекләндерү сыйфатсыз үткәрелгән, нәтиҗәдә торак бинадагы фатирларга түбәдән су үткән.

Тукай муниципаль районы Бәтке, Шилнабаш, Мәләкәс һәм Түбән Суыксу бистәләрендәге күпфатирлы 9 өйнең йомшак түбәсен һәм фасадларын төзекләндерү буенча эшләр дә кимчелекләр белән башкарылган.

Тикшерү барышында капиталь төзекләндерү буенча башкарылган эшләрнең күләмен арттырып күрсәтү фактлары ачыкланды: Казан шәһәренең Киров районында – 1 000 сумга, Алабуга муниципаль районында – 443,6 мең сумга, Питрәчтә - 211,4 мең сумга. Шулай итеп, Казан шәһәренең Киров районында балкон плитәләрен төзекләндерүдә төзү материаллары нигезсез рәвештә сызылган, 48 тәрәзә урынына фактта 24 кенә куелган.

Аерым очракларда эш башкару өчен үзенең матди-техник базасы булмаган оешмалар җәлеп ителгән. Тикшерү үткәрелгән вакытка Казан шәһәренең Киров районында 2 подряд оешмасы («Мирекс» ҖЧҖ һәм «Ремжилстрой К»ҖЧҖ) теркәлү урынында булмады, заказчы аларның кайда булуы турында мәгълүмат ала алмады. Күпфатирлы өйләрдә төзекләндерү үткәрү өчен алар үзләштергән акча күләме 76 млн тәшкил итә.

Тикшерүләр барышында Хисап палатасы **бюджет кредитларын куллану һәм кире кайтару, кичектерелгән дебитор бурычларны кире кайтару буенча чаралар күрүне тикшерүне** тормышка ашыра.

Устав капиталында Татарстан Республикасы өлеше булган ачык акционер җәмгыятьләренең финанс-хуҗалык эшчәнлегенә тикшерү үткәргәндә «Таткоммунпромкомплект» ААҖ алдында тәэмин итүчеләр һәм подрядчыларның 247 600 мең сум күләмендә кичектерелгән дебитор бурычы булуы ачыкланды. Тикшерү чарасы барышында республика лизинг фондына 202 000 мең сум кире торгызылды.

Энергетика ресурсларын Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгы һәм аңа караган учреждениеләр тарафыннан кулланганда бюджет акчаларын тотуның нәтиҗәлелегенә аудит үткәргәндә Мамадыш махсус (коррекцияле) гомуми белем бирү интернат-мәктәбе һәм Казандагы 6 номерлы махсус (коррекцияле) (Е.Г.Ласточкина исемендәге) интернат-

мәктәбен төзекләндерүгә бүленгән 1 483,5 мең сум күләмендәге акчаның 2,5 елдан артык подряд фирмасы карамагында торганлыгы ачыкланды.

Алабуга муниципаль районында 2009 елда район Советы карары белән, «Алабуга җылылык челтәрләре предприятиесе» ДУ банкротка чыгу һәм аннан бурычны түләтү мөмкинлеге булмау сәбәпле, элегрәк бюджет кредиты буенча бирелгән 22700 мең сум күләмендәге бурыч юкка чыгарыла.

Тукай муниципаль районында район Советы карары буенча авыл районның хуҗалыгы предприятиеләре алган юкка чыгарылган кредитларның гомуми күләме  43 171 мең сум тәшкил итә, бу җирле бюджет акчаларының югалуына китергән.

2009 һәм 2010 елларга җирле мәсьәләләрне чишү өчен акча тупланган республика муниципаль берәмлекләре башкарма комитетлары, резерв һәм башка төр фондларның бюджеттан тыш исәбендәге акчаларын формалаштыру һәм тотуны тикшерү Алабуга муниципаль районының «Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә ярдәм күрсәтү фонды» МУ заемщикларының тикшерү моментына түләү вакыты узган 27 килешү буенча гомуми күләме 20 900 мең сум булган бурычы булуы ачыкланды.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча Алабуга муниципаль районы прокуратурасы тарафыннан Алабуга муниципаль районы башлыгы һәм Җир-мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы җитәкчесе исеменә күрсәтмә юлланды.

Питрәч муниципаль районы бюджетына бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджет акчаларын куллануны тикшерү вакытында Россия Федерациясе бюджет кодексын бозып район башкарма комитеты җирле бюджеттан «Сердинка» ҖЧҖ нә 500 мең сум күләмендә процентсыз займ бирүе ачыкланды. Тикшерү нәтиҗәләре буенча акчалар район бюджетына кире кайтарылды.

Үткәрелгән тикшерү чаралары буенча гомуми күләме **3 035 829,8** мең сум булган **бозулар ачыклана**, шул исәптән: Татарстан Республикасы бюджеты чаралары буенча - 1 537 577,4 мең сум, муниципаль берәмлекләр бюджеты - 1 085 396,0 мең сум, Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе фонды бюджеты -  4 972,0  мең сум, республика лизинг фонды - 247 556,8 мең сум,  бюджеттан тыш акчалар буенча - 160 327,6 мең сум.

**2011 елда финанслау Татарстан Республикасы Хисап палатасы ачыклаган финанс бозулар төзелеше (чыганаклары киселешендә)**




Комплекслы һәм тематик тикшерүләр үткәрү вакытында түбәндәге бозулар ачыклана:

- дәүләт (муниципаль) мөлкәте белән идарә иткәндә бозулар - 1 417 177,3 мең сум;

Россия Федерациясе Бюджет кодексын һәм башка бюджет законмалыгы актлары таләпләрен бозу - 399 873,5 мең сум, шул исәптән бюджет чараларын тотканда җитешсезлекләр;

- «Бухгалтер исәбе турында» Федераль законын, исәпкә алу һәм хисап бирү мәсьәләләрен ачыклаучы башка норматив хокук актларын бозу - 393 716,5 мең сум, шул исәптән бюджет хисабын бозып күрсәтү, бухгалтер исәп – хисабы исәбендә һәм бухгалтер исәбе регистрларында хуҗалык операцияләрен исәпкә алу булмау;

- “Дәүләт һәм муниципаль хаҗәтләр өчен товарлар китерү, эшләр башкару һәм хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру турында” Федераль законны бозулар - 85 127,3 мең сум, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль килешүләрне төзү һәм үтәү белән бәйле мәсьәләләрдә;

- башка бозулар (мөлкәт хуҗасы рөхсәтеннән башка төп чараларны һәм милекне чыгымга чыгару, республика лизинг фонды акчаларын дебитор бурычлылыгына нигезсез тарту, расланган лимиттан югарырак йөкләмәләр кабул итү) - 717 081,8 мең сум;

- бюджет акчаларын максатсыз куллану - 22 853,4 мең сум.

## 2011 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы ачыклаган бозулар төзелеше (мең сумнарда)




Тикшерүләр нәтиҗәләре буенча бюджет акчалары белән җитәкчелек итүчеләр, бюджет процессында башка катнашучыларга 2011 елда ачыкланган бозулар буенча чаралар күрү өчен 59 күрсәтмә җибәрелде.

Бюджет акчаларын максаттан тыш куллану фактлары буенча административ хокук бозулар турында 42 протокол төзелде һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына һәм мировой судьяларга җибәрелде.

Дәүләт һәм муниципаль заказларын урнаштыру өлкәсендә ачыкланган бозулар өлешендә 11 тикшерү чарасы материаллары буенча мәгълүмат Федераль монополиягә каршы хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрелде.

Материалларны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, мировой судьялар, Татарстан Республикасы буенча Федераль монополиягә каршы хезмәт идарәсе карау нәтиҗәләре буенча 6 зат административ җаваплылыкка тартылды.

Татарстан Республикасы Прокуратурасына Хисап палатасы җибәргән материаллар буенча республиканың шәһәр һәм район прокурорлары тарафыннан башкарма хакимият органнары, оешма һәм учреждениеләр җитәкчеләре исеменә бюджет закончалыгын бозуларны бетерү буенча 42 күрсәтмә юлланды.

Татарстан Республикасы Хисап палатасы һәм прокуратура органнары күрсәтмәләре буенча дисциплинар җаваплылыкка 61 вазыйфаи зат тартылды, 8есе эштән азат ителде.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәсендә 3 җинаять эше ачылды.

Аерым алганда, Казан шәһәренең Киров районында күп квартиралы өйнне капиталь төзекләндергәндә эшләнгән эшләр күләме 1 млн. сумга арттырып күрсәтелгән. Россия  Федерациясе җинаятьләр кодексының 159 маддәсе (“Алдау”) буенча җинаять эше ачылды.

Шул ук маддә буенча җинаять эше Вахитов районында да ачыла. Торак йортны төзекләндерү буенча башкарылган эш күләме чынлыкта тотылган чыгымнарга туры килми.

Шул ук җинаять эше «Бизнес инкубатор» (Чистай шәһәре) объектында төзү-монтаж эшләре башкарганда 1,6 млн. сум күләмендә бюджет акчаларын дәлилләнмәгән куллану факты буенча кузгатылды.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча барлык дәрәҗә бюджетларга гомуми күләме **1 922 464,6** мең сум күләмендә чаралар **кире кайтарыла** һәм булган бозулар буенча **чаралар күрелә**, шулардан:

- Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетына максатчан файдаланылмаган акчалар кире кайтарылган  - 8 320,4 мең сум;
- Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетына һәм республика лизинг фондына башка төр бозулар буенча –  255 127,6 мең сум акчалар кире кайтарылган ;
- бюджет акчаларын кулланган вакытта, республика (муниципаль) милекне кулланганда ачыкланган кимчелекләрне (нәтиҗәсез эшчәнлек) бетерү һәм башка финанс бозулар буенча – 1 659 016,6 мең сум күләмендә чаралар күрелгән.

**2009-2011 елларда тикшерү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Хисап палатасы ачыклаган бозулар күләме, барлык дәрәҗә бюджетларга кире кайтарылган акча һәм күрелгән чаралар динамикасы**




Барлык үткәрелгән тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча материаллар Татарстан Республикасы Прокуратурасына җибәрелде.

2011 елда үткәрелгән тикшерү-ревизия һәм экспертиза-аналитик чаралар буенча йомгаклау документлары Хисап палатасының 25-28нче номерлы мәглүмати бюллетеньнәрендә, шулай ук Хисап палатасының интернет сайтында (http://www.sprt.ru) урнаштырылды.

## Россия Федерациясе Хисап палатасы, Россия Федерациясе субъектлары һәм муниципаль берәмлекләре тикшерү-хисап органнары белән үзара хезмәттәшлек

2011 елда Россия Федерациясе Хисап палатасы, Россия Федерациясе тикшерү-хисап органнары ассоциациясе (АКСОР) һәм Россиянең муниципаль берәмлекләре тикшерү-хисап органнары союзы белән хезмәттәшлекне үстерү һәм ныгыту буенча эш дәвам иттерелде.

Россия Федерациясе Хисап палатасы белән берлектә:

- халыкка югары технологияле медицина хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәлелегенә аудит (аудит нәтиҗәләре буенча мәгълүмат Татарстан Республикасы Дәүләт Советына һәм Татарстан Республикасы Министрлар Советына җибәрелде);

- Казанда Бөтендөнья Җәйге универсиаданы оештыру, әзерләү һәм үткәрүгә бүлеп бирелгән акчаларны тотуны тикшерү (тикшерү нәтиҗәләре Россия Федерациясе Хисап палатасы Коллегиясе утырышында каралды) үткәрелде.

Май аенда Казанда Россия Тикшерү-хисап органнары ассоциациясе Президиумының кидәйтелгән күчмә утырышы булып үтте.

Утырышта "Россия Федерациясе субъектлары һәм муниципаль берәмлекләре тикшерү-хисап органнарын оештыру һәм эшчәнлегенең төп принциплары турында" №6-ФЗ номерлы (7.02.2011) Федераль законын тормышка ашыруның аерым мәсьәләләре каралды

Тикшерү-хисап органнарына методик һәм консультацион ярдәм күрсәтү максатыннан, Россия Хисап палатасы һәм Ассоциация тарафыннан Россия Федерациясе субъекты тикшерү-хисап органы турында модель закон һәм муниципаль берәмлек тикшерү-хисап палатасы турында модель нигезләмәсе эшләнде һәм регионнарга җибәрелде.

Май аенда Казанда Россия Федерациясе тикшерү-хисап органнары арасында бадминтон буенча Россия чемпионаты булып үтте. Ярышта федераль округларда Россия Тикшерү-хисап органнары ассоциациясе (АКСОР) бүлекләрен тәкъдим итүче 11 команда, шулай ук Россиянең муниципаль тикшерү- хисап органнары союзы, Россия Федерациясе Хисап палатасы һәм Татарстан Республикасы Хисап палатасы командалары катнашты. Ярыш нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Хисап палатасы командасы тикшерү-хисап органнары арасында Россия чемпионы булып танылды.

Татарстан Республикасы Хисап палатасы вәкилләре дәүләт финанс тикшерүен камилләштерү мәсьәләләренә багышланган АКСОР ның XVII һәм XVIII конференцияләрендә, фәнни-гамәли конференцияләрдә һәм түгәрәк өстәлләрдә катнашты.

Россия Федерациясе Системалы анализның дәүләт фәнни-тикшеренү институты эш планына туры китереп, Татарстан Республикасы Хисап

палатасы эшче группасы тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүгә юлланган бюджет акчаларын тотуның нәтиҗәлелегенә аудит буенча методик рекомендацияләр, шулай ук бюджет чараларының төп оештыручыларын эчке тикшерү системаларын регион дәрәҗәсендә бәяләү буенча методик рекомендацияләр эшләнде.

Татарстан Республикасы Хисап палатасы вәкилләре Россия Федерациясе Хисап палатасында үткән сәламәтлек саклау өлкәсендә нәтиҗәлелеккә аудит практикасы һәм үсеш методологиясе мәсьәләләре буенча Россия – Британия семинарында катнашты.

Финанс тикшерүе регион органнарының Европа ассоциациясе (ЕВРОРАИ) әгъзасы буларак, Татарстан Республикасы Хисап палатасы әлеге оешма үткәргән чараларда катнаша.

Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе 2011 елның маенда Россия делегациясе составында дәүләт идарәсе мәсьәләләре буенча ЕВРОРАИның халыкара семинарында катнашты. Семинарда Европа илләре регионнарында, шул исәптән Россия Федерациясендә (Мәскәү, Санкт-Петербург, Дондагы Ростов) тышкы финанс тикшерүен тормышка ашыручы дәүләт администрацияләре һәм оешмалары делегатлары катнашты. Тәҗрибә алмашу булды, хәзерге заман кризисы һәм аңа юлдаш булып торган дәүләт бюджеты дефициты шартларында икътисадның дәүләт секторын тышкы яктан тикшерү һәм бюджетны планлаштыру, финанс исәбе өлкәсендәге перспективалар турында фикер алышулар булды.

Октябрь аенда Хисап палатасы вәкилләре ЕВРОРАИның беренче тапкыр Россиядә (Дондагы Ростов шәһәре) үткәрелгән чираттагы халыкара семинарында катнаштылар.

Семинар эше тематик сессияләр буенча төзелгән иде, алар барышында муниципаль хакимият органнарында үткәрелә торган аудитның төрле аспектлары: бюджет үтәлешен муниципаль дәрәҗәдә тикшерү, муниципаль милекне куллануны тикшерү, дефицит һәм муниципаль берәмлекләр бюджетларының бурыч йөкләмәләре тикшерелде.

“Муниципаль милекне куллануны тикшерү, икътисади методлар һәм нәтиҗәлелек критерийлары” сессиясе кысаларында муниципаль милекне һәм бюджет акчаларын җирле дәрәҗәдә куллануны тикшерүне оештыру һәм үткәрү буенча Татарстан Республикасы Хисап палатасы эшчәнлеге турында

доклад белән Татарстан Республикасы Хисап палатасы аудиторы чыгыш ясады.

2011 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы вәкилләре Татарстан Республикасы Президенты каршындагы дәүләт эшчеләре департаменты, Идел буе һәм Себер федераль округларында Россия Федерациясе системалы анализ Фәнни-тикшеренү институтының филиаллары, Россия Федерациясе Президенты каршындагы Россия дәүләт хезмәте Академиясе оештырган Россия Федерациясе субъектлары тикшерү-хисап органнары хезмәткәрләре өчен белем күтәрү курсларында нәтиҗәлелек аудитын үткәрү буенча Татарстан Республикасы Хисап палатасы эш тәҗрибәсе турында чыгыш ясадылар.

Хисап елында республиканың муниципаль берәмлекләр тикшерү-хисап органнары белән хезмәттәшлек дәвам итте.

Татарстан Республикасы Хисап палатасы һәм муниципаль берәмлекләр тикшерү-хисап органнары вәкилләре Идел буе округында АКСОР бүлеге эшчәнлеге кысаларында оештырылган муниципаль тышкы тикшерүне үстерү мәсьәләләре буенча түгәрәк өстәл эшендә, шулай ук Россия муниципаль тикшерү-хисап органнары Союзының X конференциясендә катнашты.

2011 елда Татарстан Республикасы тикшерү-хисап органнары Советының 3 утырышы булды. Утырышларда республика муниципаль берәмлекләрендә үткәрелгән тикшерү чараларының төп нәтиҗәләре; муниципаль тикшерү-хисап органнары турындагы нигезләмәләрне 2011 елның 7 февралендә кул куелган 6-ФЗ номерлы “Россия Федерациясе субъектлары һәм муниципаль берәмлекләр тикшерү-хисап органнарын оештыру һәм эшчәнлеге төп принциплары турында” Федераль законына туры китерү; коррупциоген факторлар һәм куркынычлык мониторингын үткәрү; муниципаль тикшерү-хисап органнары эшчәнлегендә мәгълүмати технологияләр куллану каралды.

Муниципаль тикшерү-хисап органнары җитәкчеләре 2011 елның июлендә бюджет, салым һәм финанслар буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы оештырган семинар-киңәшмәдә катнашты. Семинар-киңәшмәдә чираттагы финанс елына муниципаль дәрәҗәдә бюджет формалаштыру, автоном, бюджет һәм казна оешмалары эшчәнлеген тикшерүне оештыру мәсьәләләре каралды. Семинар эшендә Татарстан Республикасы Хисап палатасы, Татарстан Республикасы Финанс

министрлыгы, Татарстан Республикасы буеча Россия Федераль салым хезмәте идарәсе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршында Татарстан Республикасы иктисади һәм иҗтимагый тикшеренүләр үзәге вәкилләре катнашты.

Совет эше кысаларында ай саен муниципаль берәмлекләренең тикшерү-хисап органнары эшчәнлегенә мониторинг ясау тормышка ашырыла.

Хисап елында муниципаль берәмлекләре тикшерү-хисап органнарына юридик зат хокуклары бирү процессы төгәлләнде – барлык палаталар юридик зат булып санала, хәзерге заман компьютер техникасы белән тәэмин ителде.

Муниципаль тикшерү-хисап органнарына оештыру, хокук, методик һәм мәгълүмати, шул исәптән бюджет акчаларын куллануның нәтиҗәлелегенә аудитны оештыру һәм үткәрү буенча ярдәм күрсәтелә.

Совет эшчәнлеге, норматив һәм методик документлар, квалификация күтәрү курслары буенча мәгълүмат Татарстан Республикасы тикшерү-хисап органнары Советының рәсми сайтына урнаштырыла (http://www.ksort.ru).

## Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм хокук саклау органнары белән хезмәттәшлек

Республика территориясендә дәүләт финанс тикшерүе органнары хезмәттәшлеген оештыру Татарстан Республикасында дәүләт финанс тикшерүе мәсьәләләре буенча Ведомствоара координацияләү советы кысаларында Тикшерү чараларының җыелма планы белән бәйләп алып барылды, бу исә тикшерү органнары эшендә кабатлануны булдырмаска мөмкинлек бирде. Финанс-бюджет өлкәсендә бозуларны кисәтү һәм булдырмау максатында ел саен республика министрлыклары, ведомство һәм муниципаль берәмлекләренә җитешмәүчелек һәм бозуларны системалаштыру һәм анализ нәтиҗәләре буенча Бәяләмә, шулай ук дәүләт (муниципаль) финанс тикшерүе барышында ачыкланган бозу һәм җитешмәүчелекләр Классификаторы җибәрелә.

Татарстан Республикасы Президенты Указлары белән Положение һәм Совет составына да үзгәрешләр кертелә.

Совет утырышларында коррупциягә каршы тору өлкәсендә тикшерү һәм хокук саклау органнарының бергәләп эшләү, бер көнлек фирмалар буенча

бердәм мәгълүмат базасын төзү, дәүләт һәм муниципаль заказларны урнаштырганда башлангыч бәяләрне тикшерү юнәлешләре билгеләнә.

2010 елда Росфиннадзор, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең урындагы идарәләре, Финанс министрлыгының Казначылык департаменты, Республика Прокуратурасы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы үткәргән тикшерү чаралары нәтиҗәләрен анализлау йомгаклары буенча Хисап палатасы характерлы бозулар һәм җитешмәүчелекләр (500 төрдән артык) буенча Бәяләмә әзерләде һәм кисәтү һәм булдырмау чаралары үткәрү өчен Татарстан Республикасының барлык министрлыклары, ведомство һәм муниципаль берәмлекләренә җибәрде.

Ведомствоара координация советы тарафыннан 83-ФЗ номерлы федераль законга бәйле рәвештә хокукый хәлен камилләштерү буенча үткәрелүче реформа шартларында автоном, бюджет һәм казна учреждениеләре эшчәнлеген тикшерүне оештыру Концепциясе каралды һәм расланды. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эчке аудит хезмәтләренә тәкъдим сыйфатында Концепцияне башкарма хакимият органнарына җибәрде.

Татарстан Республикасында дәүләт финанс тикшерүе мәсьәләләре буенча Ведомствоара координациялəү советы эшчәнлеге кысаларында Татарстан Республикасы Хисап палатасы 2009-2010 еллар өчен республика башкарма хакимияте органнарының ведомство эчендә финанс тикшерүе бүлекчәләре эшенең төп нәтиҗәләренә мониторинг һәм анализлау үткәрде.

Хисап палатасы республика Прокуратурасы белән берлектә муниципаль берәмлекләр башкарма комитетларының бюджеттан тыш исәбендәге акчаларны формалаштыру һәм тотуны тикшерде.

Хисап палатасы, Финанс министрлыгының Казначылык департаменты, Финанс-бюджет күзәтчелеге федераль хезмәтенең Территориаль Идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан ачыкланган бюджет законнарын бозу буенча мәгълүмат квартал саен гомумиләштерелеп барылды.

## Эшчәнлектә хәбәрдарлык

Татарстан Республикасы Хисап палатасы эшчәнлеге, Хисап палатасының Коллегия, Татарстан Республикасында дәүләт финанс тикшерүе мәсьәләләре буенча ведомствоара координациялəү Советы һәм Татарстан

Республикасы тикшерү-хисап органнары Советы утырышлары һәрдаим массакүләм матбугат чаралары тарафыннан, шул исәптән федераль басмаларда да яктыртылып торды.

Татарстан Республикасы Хисап палатасы эшчәнлеге турында мәгълүмат рәсми сайтта (http://www.sprt.ru), Россия тикшерү-хисап органнары ассоциациясенең “Россия Хисап палаталары” сайтында (http://www.ach-fci.ru), шулай ук федераль мәгълүмат агентлыклары сайтларында (РИА-Новости, Интерфакс-Поволжье, Прайм-ТАСС, ИТАР-ТАСС, РЕГНУМ һ.б) урнаштырылды.

2011 елда Хисап палатасы сайтына 17 135 тапкыр керү теркәлгән (2010 елда – 12 790, 2009 елда – 10 989 мәртәбә).

2011 елда массакүләм мәгълүмат чараларында (интернет-басмалар, журналлар, газеталар һәм телевидениедә) Хисап палатасы эшчәнлеге 278 материал һәм телесюжетта тәкъдим ителде (2010елда – 257, 2009 елда – 223 материал).

Үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча йомгаклау документлары, Хисап палатасы эшчәнлеге елъязмасы Татарстан Республикасы Хисап палатасының квартал саен чыгып килүче мәгълүмат бюллетеньнарында урын алды. Хисап палатасы бюллетеньнары Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасында Дәүләт финанс тикшерүе мәсьәләләре буенча ведомствоара координацияләү советы әгъзаларына юлланды.